**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30.12.2021** **№ 1080**

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Хезмәт хаклары Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Биектау муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 06 июлендәге 1990 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Хезмәт хаклары Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган муниципаль берәмлек учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү системасын камилләштерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 30 октябрендәге 1029 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Хезмәт хаклары Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Биектау муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 06 июлендәге 1990 номерлы карарына (Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 24.10.2011 №3129, 16.11.2012 №3047, 11.11.2013 №2616, 10.11.2015 №1918, 16.01.2018 №155 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

күрсәтелгән карарга 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: Р. Ф.Хисамутдинов

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 30 декабрендәге 1080 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлары), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 13 617,0 |
| 2 | 1,0178 | 13 860,0 |
| 3 | 1,0362 | 14 110,0 |
| 4 | 1,0538 | 14 350,0 |
| 5 | 1,0736 | 14 620.0 |
| 6 | 1,0927 | 14 880,0 |
| 7 | 1,1133 | 15 160,0 |
| 8 | 1,1331 | 15 430,0 |
| 9 | 1,1530 | 15 700,0 |
| 10 | 1,1743 | 15 990,0 |
| 11 | 1,1048 | 16 270,0 |
| 12 | 1,2168 | 16 570,0 |
| 13 | 1,2389 | 16 870,0 |
| 14 | 1.2609 | 17 170,0 |
| 15 | 1,2837 | 17 480,0 |
| 16 | 1,3072 | 17 800.0 |
| 17 | 1,3307 | 18 120,0 |
| 18 | 1,3549 | 18 450,0 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 - 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә